**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Об утверждении Положения о порядке вручения государственных наград Республики Татарстан

В соответствии с частью 4 статьи 25 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемое Положение о порядке вручения государственных наград Республики Татарстан.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить в установленном порядке финансирование расходов на изготовление знамени, используемого при вручении ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» награжденным организациям и их подразделениям.

3. Управлению делами Президента Республики Татарстан обеспечить изготовление знамени, используемого при вручении ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» награжденным организациям и их подразделениям.

4. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
13 июня 2018 года
№ УП-424

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «13» июня 2018 года

№ УП-424

**Положение**
**о порядке вручения государственных наград Республики Татарстан**

1. Настоящим Положением устанавливается порядок вручения государственных наград Республики Татарстан гражданам Российской Федерации, иностранным гражданам, лицам без гражданства (далее – граждане), а также организациям и их подразделениям (далее – организации).

2. Государственные награды Республики Татарстан вручает Президент Республики Татарстан.

3. По поручению Президента Республики Татарстан и от его имени государственные награды Республики Татарстан могут вручать:

Председатель Государственного Совета Республики Татарстан, заместители Председателя Государственного Совета Республики Татарстан;

Премьер-министр Республики Татарстан, заместители Премьер-министра Республики Татарстан;

Руководитель Аппарата Президента Республики Татарстан;

министры, председатели государственных комитетов, руководители иных республиканских органов исполнительной власти;

главы муниципальных районов (городских округов).

4. Президент Республики Татарстан может поручить вручение государственных наград Республики Татарстан и иным лицам.

5. Вручение государственных наград Республики Татарстан обеспечивается отделом государственных наград Аппарата Президента Республики Татарстан (далее – Отдел наград), Управлением государственного протокола Президента Республики Татарстан совместно с государственными органами Республики Татарстан, органами местного самоуправления и организациями, в которых производится вручение государственных наград Республики Татарстан.

6. Государственные награды Республики Татарстан вручаются в обстановке торжественности и широкой гласности не позднее трех месяцев со дня издания указа Президента Республики Татарстан о награждении.

Вручение государственных наград Республики Татарстан производится в следующей последовательности:

орден «За заслуги перед Республикой Татарстан»;

орден «Дуслык»;

медаль ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан»;

медаль «За доблестный труд»;

медаль «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан»;

медаль «Ана даны – Материнская слава»;

медаль «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны нефти Татарстана»;

почетные звания Республики Татарстан.

Для выноса государственной награды Республики Татарстан к месту вручения назначаются ассистенты.

Перед вручением государственных наград Республики Татарстан зачитывается указ Президента Республики Татарстан о награждении.

После оглашения указа Президента Республики Татарстан о награждении награжденный выходит к лицу, осуществляющему вручение государственной награды Республики Татарстан, и встает с левой стороны от него.

Лицо, осуществляющее вручение государственной награды Республики Татарстан, принимает от ассистента государственную награду Республики Татарстан и прикрепляет ее на левую сторону груди награждаемого (ордена, медали) или на правую сторону (знаки к почетным званиям).

7. При вручении награжденным организациям ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» (далее – Орден) используется знамя, описание которого приведено в приложении № 1.

Для выноса знамени к месту вручения Ордена назначаются знаменщик (знаменная группа) и ассистенты.

В процессе награждения знаменщик (знаменная группа) стоит справа от лица, осуществляющего вручение Ордена, а ассистент, выносящий Орден, – слева.

Орден вручается руководителю организации или уполномоченному им лицу, как правило, в присутствии коллектива награжденной организации.

Для получения Ордена приглашаются руководитель организации или уполномоченное им лицо, которых могут сопровождать представители трудового коллектива и ветераны организации.

После оглашения указа Президента Республики Татарстан о награждении знаменщик выходит вперед и ставит знамя к правой ноге вертикально.

Лицо, осуществляющее вручение Ордена, принимает его от ассистента и подходит к знамени.

Знаменщик наклоняет знамя и держит его обеими руками горизонтально перед собой.

Лицо, осуществляющее вручение Ордена, прикрепляет его на лицевую сторону знамени к левому верхнему углу.

После прикрепления Ордена знаменщик передает знамя лицу, осуществляющему вручение Ордена.

Знамя вместе с Орденом вручается руководителю организации или уполномоченному им лицу.

Церемония вручения Ордена завершается исполнением Государственного гимна Республики Татарстан.

8. В ходе церемонии награждения государственными наградами Республики Татарстан осуществляется фото- и видеосъемка, а также церемония награждения может сопровождаться торжественной мелодией.

9. Награжденным гражданам и организациям в процессе или после окончания церемонии награждения вручается удостоверение к государственной награде Республики Татарстан.

10. В случае вручения государственных наград Республики Татарстан должностными лицами, указанными в пункте 3 настоящего Положения, Отдел наград направляет государственные награды Республики Татарстан и документы к ним в государственные органы Республики Татарстан или органы местного самоуправления для вручения в соответствии с поручением Президента Республики Татарстан и указами Президента Республики Татарстан о награждении.

11. В случае если Президентом Республики Татарстан вручение государственных наград Республики Татарстан поручено лицам, указанным в пункте 4 настоящего Положения, Отдел наград направляет государственные награды Республики Татарстан и документы к ним этим лицам для вручения в соответствии с указами Президента Республики Татарстан о награждении.

12. О произведенном вручении государственных наград Республики Татарстан составляется протокол вручения государственных наград Республики Татарстан и документов к ним (далее – протокол вручения) в двух экземплярах по форме согласно приложению № 2, а также оформляется расписка о получении государственной награды Республики Татарстан и документа к ней по форме согласно приложению № 3.

Протокол вручения сверяется с указом Президента Республики Татарстан о награждении, подписывается лицом, вручившим государственную награду Республики Татарстан, или руководителем государственного органа Республики Татарстан, органа местного самоуправления, организации, где производилось вручение, или уполномоченным членом Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан и скрепляется соответствующей печатью.

13. При посмертном награждении или в случае смерти награжденного, которому при жизни государственная награда Республики Татарстан не была вручена, государственная награда Республики Татарстан и документ к ней передаются (вручаются) для хранения как память супруге (супругу), отцу, матери, сыну, дочери, брату, сестре, дедушке, бабушке или одному из внуков награжденного лица.

Передача оформляется протоколом передачи (вручения) государственной награды Республики Татарстан и документа к ней семье посмертно награжденного (умершего награжденного) (далее – протокол передачи) в двух экземплярах по форме согласно приложению № 4, а также

распиской о получении государственной награды Республики Татарстан и документа к ней по форме согласно приложению № 3.

14. Первые экземпляры протоколов вручения и протоколов передачи, а также расписки о получении государственной награды Республики Татарстан и документа к ней передаются в Отдел наград.

Вторые экземпляры протоколов вручения и протоколов передачи подлежат постоянному хранению в соответствующих государственных органах Республики Татарстан и органах местного самоуправления.

15. Отдел наград совместно с государственными органами Республики Татарстан и органами местного самоуправления, в которых производится вручение государственных наград Республики Татарстан, осуществляет контроль за вручением государственных наград Республики Татарстан, ведет персональный учет награжденных, которым не вручены государственные награды Республики Татарстан, выясняет причины неврученния, принимает меры к последующему вручению государственных наград Республики Татарстан.

В случае если награжденный вследствие болезни или инвалидности не может явиться на вручение, государственная награда Республики Татарстан вручается ему по месту жительства или в лечебном учреждении, где он находится.

Списки награжденных, которым не представилось возможным вручить государственные награды Республики Татарстан, составленные по форме согласно приложению № 5, с указанием причин неврученния направляются в Отдел наград вместе с неврученными государственными наградами Республики Татарстан и документами к ним.

Приложение № 1
к Положению о порядке
вручения государственных
наград Республики Татарстан

**Описание**
**знамени, используемого при вручении ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» награжденным организациям и их подразделениям**

Знамя, используемое при вручении ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» награжденным организациям (далее – наградное знамя), представляет собой знаменный комплекс, в состав которого входят двустороннее полотнище, древко, навершие и подток.

Полотнище наградного знамени прямоугольное, размером 110 x 165 см, с запасом для крепления к древку 6,5 см. Изготовлено из сложенного вдвое бархата пурпурного цвета и по краям с трех сторон обшито золотистой шелковой бахромой длиной 6 см.

В центре лицевой стороны полотнища цветным шелком вышито изображение знака ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» размером 50 см в диаметре.

На оборотной стороне полотнища сверху цветным шелком вышита надпись «За заслуги перед Республикой Татарстан», снизу надпись «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен». Высота строчных букв – 5,4 см, прописных – 6,6 см.

Древко наградного знамени деревянное, круглого сечения, окрашено в темно-коричневый цвет. Диаметр древка – 3,5 см, длина – 270 см.

Навершие деревянное, пурпурного цвета, в виде пики. Высота навершия – 28 см.

Подток в виде усеченного конуса высотой 9 см.

___

Приложение № 2
к Положению о порядке
вручения государственных
наград Республики Татарстан

**ПРОТОКОЛ**
**вручения государственных наград Республики Татарстан**
**и документов к ним**

_____________________________ «_____» ___________ ______ г.
(место вручения) (дата вручения)

Мною, ____________________________________________________________

________________________________________________________________________,
(должность, фамилия и инициалы лица, вручившего награды)

от имени Президента Республики Татарстан вручены государственные награды Республики Татарстан следующим лицам (организациям):

| № п/п | Фамилия, имя, отчество (при наличии) награжденного лица (наименование награжденной организации) | Вид и наименование награды | Номер награды* | Номер удостоверения* | Дата и номер указа о награждении |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

_______________________________
(подпись лица, вручившего награды)

Место
печати

* Заполняется при вручении ордена, медали ордена и медали Республики Татарстан.

Приложение № 3
к Положению о порядке
вручения государственных
наград Республики Татарстан

**РАСПИСКА**
**о получении государственной награды Республики Татарстан**
**и документа к ней**

Мною, ______________________________________________________________,
(фамилия, имя, отчество (при наличии) лица, получившего государственную награду Республики Татарстан, или представителя награжденной организации с указанием должности)

в соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от
«______» ____________________ ____________г. № ____________________

получены ___________________________________________________________

____________________________________________________________________
(наименование и номер награды, номер удостоверения)

«_____» _______________ _______ г. ______________________________
(подпись)

___________

Приложение № 4
к Положению о порядке
вручения государственных
наград Республики Татарстан

**ПРОТОКОЛ**
**передачи (вручения) государственной награды Республики Татарстан и документа к ней семье посмертно награжденного (умершего награжденного)**

«_____» ______________ _______г. мною, ______________________________

_____________________________________________________________________
(должность, фамилия и инициалы лица, передавшего награду)

_____________________________________________________________________,

переданы _____________________________________________________________
(кому (степень родства, фамилия, имя, отчество (при наличии) лица, принявшего награду)

_____________________________________________________________________
(наименование и номер награды, номер удостоверения)

посмертно награжденного (умершего награжденного) Указом Президента Республики Татарстан от «_____» ____________ ______ г. № _________

_____________________________________________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии) награжденного)

______________________________
(подпись лица, передавшего награду)

Место
печати

___________

Приложение № 5
к Положению о порядке
вручения государственных
наград Республики Татарстан

# СПИСОК
## награжденных, которым не представилось возможным вручить государственные награды Республики Татарстан

по ______________________________________________
(государственный орган Республики Татарстан, орган местного самоуправления)

| № п/п | Фамилия, имя, отчество (при наличии) награжденного (наименование награжденной организации) | Дата и номер указа о награждении | Вид и наименование награды | Причины неврученияˣ |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

______________________________________________
(должность, фамилия, имя, отчество (при наличии) лица, подписавшего список)

_______________
(подпись)

«____» ______________ _______ г.

Место
печати

* Причины невручения: выбыл на новое место жительства (адрес нового места жительства); перешел на новое место работы (указать новое место работы); умер (родственников нет); в командировке за рубежом (срок возвращения); призван на действительную военную службу (город, номер в/ч) и другие причины.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы 4 кисәге нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бүләкләнгән оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденын тапшырганда файдаланыла торган байракны әзерләүгә чыгымнарны тиешле тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенә бүләкләнгән оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденын тапшырганда файдаланыла торган байракны әзерләүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июнь
№ ПУ-424

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «13» июнендәге
ПУ-424 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәгә таянып Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына, гражданлыгы булмаган затларга (алга таба – гражданнар), шулай ук оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә (алга таба – оешмалар) Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен Татарстан Республикасы Президенты тапшыра.

3. Татарстан Республикасы Президенты йөкләве буенча һәм аның исеменнән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләр тапшырырга мөмкин:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең урынбасарлары;

Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министрының урынбасарлары;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе;

министрлар, дәүләт комитетлары рәисләре, башкарма хакимиятнең башка республика органнары җитәкчеләре;

муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыклары.

4. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыруны башка затларга да йөкләргә мөмкин.

5. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге (алга таба – Дәүләт бүләкләре бүлеге), Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе тарафыннан аларда Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре тапшырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән бергә тәэмин ителә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указы чыгарылган көннән өч айдан да соңга калмыйча тантаналы шартларда һәм киң җәмәгатьчелеккә таныту шартларында тапшырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру түбәндәге эзлеклелектә алып барыла:

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены;

«Дуслык» ордены;

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале;

«Фидакарь хезмәт өчен» медале;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале;

«Ана даны – Материнская слава» медале;

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале;

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен алар тапшырыла торган урынга алып чыгу өчен ассистентлар билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру алдыннан Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указы укыла.

Татарстан Республикасы Президенты указы укылганнан соң бүләкләнүче Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшыручы зат янына чыга һәм аның сул ягына баса.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшыручы зат ассистенттан Татарстан Республикасы дәүләт бүләген ала һәм аны бүләкләнүче күкрәгенең сул ягына (орден, медаль) яисә уң ягына (мактаулы исемнәрнең күкрәк билгеләре) тага.

7. Бүләкләнгән оешмаларга «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденын (алга таба – Орден) тапшырганда тасвирламасы 1 нче кушымтада бирелгән байрак файдаланыла.

Байракны Орденны тапшыра торган урынга алып чыгу өчен байракчы (байракчылар төркеме) һәм ассистентлар билгеләнә.

Бүләкләү барышында байракчы (байракчылар төркеме) Орден тапшыручы затның уң ягында, ә Орденны алып чыгучы ассистент аның сул ягында тора.

Орден оешма җитәкчесенә яисә ул вәкаләт биргән затка, кагыйдә буларак, бүләкләнгән оешманың коллективы алдында тапшырыла.

Орденны алу өчен оешманың җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән зат чакырыла, алар белән бергә хезмәт коллективы вәкилләре һәм оешма ветераннары килергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указы укылганнан соң байракчы алга чыга һәм байракны уң аягы янына вертикаль рәвештә бастырып куя.

Орденны тапшыручы зат аны ассистенттан кабул итеп ала һәм байрак янына килә.

Байракчы байракны авыштыра һәм аны үз алдында горизонталь рәвештә ике куллап тота.

Орден тапшыручы зат аны байракның алгы ягының өске сул як почмагына беркетә.

Орден беркетелгәннән соң байракчы байракны Орден тапшыручы затка бирә.

Орденлы байрак оешма җитәкчесенә яисә ул вәкаләт биргән затка тапшырыла.

Орден тапшыру тантанасы Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын башкару белән тәмамлана.

8. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы вакытында фотога һәм видеога төшерү оештырылырга, шулай ук тантаналы көй яңгырарга мөмкин.

9. Бүләкләнгән гражданнарга һәм оешмаларга бүләкләү тантанасы барышында яисә ул тәмамлангач Татарстан Республикасы дәүләт бүләгенә таныклык тапшырыла.

10. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре әлеге Нигезләмәнең 3 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган очракта, Дәүләт бүләкләре бүлеге Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен һәм аларның документларын Татарстан Республикасы Президенты йөкләве һәм Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указлары нигезендә тапшыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына юллый.

11. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән затларга йөкләнгән булса, Дәүләт бүләкләре бүлеге Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указлары нигезендә тапшыру өчен әлеге затларга җибәрә.

12. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре тапшырылу турында Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен һәм аларның документларын тапшыру беркетмәсе (алга таба – тапшыру беркетмәсе) 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча ике нөсхәдә тутырыла, шулай ук 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм аның документын алу турындагы язу рәсмиләштерелә.

Тапшыру беркетмәсенең Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указы белән тәңгәллеге тикшерелә, аңа Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшырган зат яисә бүләк тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма җитәкчесе яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенең вәкаләт бирелгән әгъзасы кул куя һәм тиешле мөһер сугыла.

13. Бүләк затка вафатыннан соң тапшырылса яисә бүләкләнгән зат вафат булып, аңа Татарстан Республикасы дәүләт бүләге исән вакытында тапшырылмаган булса, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге һәм аның документы истәлек итеп саклар өчен хатынына (иренә), әтисенә, әнисенә, улына, кызына, абыйсына, апасына, энесенә, сеңлесенә, әбисенә, бабасына яисә бүләкләнгән зат оныкларының берсенә бирелә (тапшырыла).

Бүләкне бирү (тапшыру) 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча ике нөсхәдә төзелгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм аның документын вафатыннан соң бүләкләнгән (бүләкләнгәннән соң вафат булган) затларның гаиләсенә бирү (тапшыру) беркетмәсе (алга таба – бирү беркетмәсе), шулай ук 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм аның документын алган затның бүләкне алу турындагы язуы белән рәсмиләштерелә.

14. Тапшыру беркетмәләренең һәм бирү беркетмәләренең, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм аның документын алу турындагы язуның беренче нөсхәләре Дәүләт бүләкләре бүлегенә тапшырыла.

Тапшыру беркетмәләренең һәм бирү беркетмәләренең икенче нөсхәләре Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында даими саклanырга тиеш.

15. Аларда Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре тапшырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән бергә Дәүләт бүләкләре бүлеге Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыруны контрольдә тота, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре тапшырылмаган бүләкләнүчеләрне персональ исәпкә ала, бүләк тапшырылмауның сәбәпләрен ачыклый, киләчәктә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру чараларын күрә.

Бүләкләнүче авыруы яисә инвалидлыгы сәбәпле бүләк тапшыруга килә алмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге аңа яшәгән урынында яисә ул дәвалана торган учреждениедә тапшырыла.

5 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру мөмкинлеге чыкмаган бүләкләнүчеләр исемлеге, бүләк тапшырылмауның сәбәпләре күрсәтелеп, тапшырылмаган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре һәм аларның документлары белән бергә Дәүләт бүләкләре бүлегенә юллана.

Татарстан Республикасы дәүләт
бүләкләрен тапшыру тәртибе
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Бүләкләнгән оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденын тапшырганда файдаланыла торган байракның тасвирламасы**

Бүләкләнгән оешмаларга «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденын тапшырганда файдаланыла торган байрак (алга таба – бүләкләү байрагы) ике яклы тукыма, сап, очлык һәм аслыктан торган байрак комплексыннан гыйбарәт.

Бүләкләү байрагының тукымасы турыпочмаклы, 110 х 165 см үлчәмендә, сапка беркетү өчен 6,5 см запас белән икегә бөкләнгән куе кызыл бәрхеттән ясала һәм өч як кырыеннан 6 см озынлыктагы алтынсу ефәк чук белән каймалана.

Тукыманың алгы ягында уртада төсле ефәк җепләр белән 50 см диаметрлы «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены билгесе сурәте чигелә.

Тукыманың арткы ягында өстә төсле ефәк җепләр белән: «За заслуги перед Республикой Татарстан» дигән язу, аста: «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» дигән язу чигелә. Юл хәрефләренең биеклеге – 5,4 см, баш хәрефләрнең биеклеге – 6,6 см.

Бүләкләү байрагының сабы агачтан ясала, түгәрәк кисемле, куе көрән төскә буяла. Сапның диаметры – 3,5 см, озынлыгы – 270 см.

Очлык – агачтан ясалган, куе кызыл төстә, сөңгесыман. Очлыкның биеклеге – 28 см.

Аслык 9 см биеклектәге кисек конус рәвешендә була.

Татарстан Республикасы дәүләт
бүләкләрен тапшыру тәртибе
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен һәм аның документларын тапшыру**
**БЕРКЕТМӘСЕ**

_________________________ ______ елның «____» ______________
(тапшыру урыны) (тапшыру датасы)

Мин, ______________________________________________________________

______________________________________________________________________
(бүләкне тапшырган затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Татарстан Республикасы Президенты исеменнән түбәндәге затларга (оешмаларга) дәүләт бүләкләре тапшырдым:

| т/с | Бүләкләнгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (бүләкләнгән оешманың атамасы) | Бүләкнең төре һәм атамасы | Бүләкнең номеры* | Таныклыкның номеры* | Бүләкләү турында указның датасы һәм номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

______________________________
(бүләкләрне тапшырган затның имзасы)

Мөһер
урыны

* Татарстан Республикасы орденын, орден медален һәм медален тапшырганда тутырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт
бүләкләрен тапшыру тәртибе
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм
аның документын алу турындагы
ЯЗУ**

Мин, ____________________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт бүләге алган затның яисә бүләкләнгән оешманың вазыйфасы күрсәтелгән вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

Татарстан Республикасы Президентының _____ елның «____» ___________ ПУ-_____ номерлы Указы нигезендә

____________________________________________________________

____________________________________________________________алдым.
(бүләкнең атамасы һәм номеры, таныклыкның номеры)

_______ елның «______» _______________ ___________________________
(имза)

__________

Татарстан Республикасы дәүләт
бүләкләрен тапшыру тәртибе
турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм аның документын вафатыннан соң бүләкләнгән (бүләкләнгәннән соң вафат булган) затның гаиләсенә бирү (тапшыру)**
**БЕРКЕТМӘСЕ**

______ елның «_____» __________________ мин, __________________________

______________________________________________________________________
(бүләкне тапшыручы затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)
______________________________________________________________________,

Татарстан Республикасы Президентының _____ елның «____» _______________

ПУ-_____ номерлы Указы нигезендә вафатыннан соң бүләкләнгән

(бүләкләнгәннән соң вафат булган)_____________________________________

______________________________________________________________________
(бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

______________________________________________________________________
(бүләкнең атамасы һәм номеры, таныклыкның номеры)

_______________________________________________________________тапшырдым.
(кемгә (туганлык дәрәҗәсе, бүләкне кабул итеп алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

____________________________
(бүләкне тапшырган затның имзасы)

Мөһер
урыны

___________

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшыру мөмкинлеге чыкмаган бүләкләнүчеләр ИСЕМЛЕГЕ**

____________________________________________буенча
(Татарстан Республикасы дәүләт органы, җирле үзидарә органы)

| т/с | Бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (бүләкләнүче оешманың атамасы) | Бүләкләү турында указның датасы һәм номеры | Бүләкнең төре һәм атамасы | Бүләк тапшырылмауның сәбәпләре* |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

______________________________________________________________________
(исемлеккә кул куйган затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

______________________
(имза)

________ елның «_____» ___________________

Мөһер
урыны

---

* Бүләк тапшырылмауның сәбәпләре: яңа тору урынына күчү (яңа тору урынының адресы); яңа эш урынына күчү (яңа эш урынын күрсәтергә); вафат булу (туганнары булмаса); чит илдә эш сәфәрендә булу (кайту вакыты); гамәлдәге хәрби хезмәткә чакырылу (х/ч урнашкан шәһәр, номеры) һәм башка сәбәпләр.

______________